КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 31 июль г.Казань № 605

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибе турында» 2021 ел, 3 сентябрь, 808 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 19 гыйнвар, 20 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасын һәм Татарстан Республикасы бюджетының бердәм счетындагы вакытлыча файдаланылмый торган акчаны банк депозитларына урнаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктта:

«ж» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ж) салым органының мөрәҗәгатьне җибәрү датасына кадәр 20 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага карата бирелгән кредит оешмасы тарафыннан

салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча йөкләмә үтәлеше турында белешмә кәгазе, ә кредит оешмасы тарафыннан салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмә булган очракта, салым органының мөрәҗәгатьне җибәрү датасына кадәр 20 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага карата бирелгән белешмә кәгазен булдыру датасына кредит оешмасының бердәй салым счетындагы уңай, тискәре яисә нуль сальдо булу турында белешмә кәгазе теркәлә;

«и» пунктчасында «Кредит оешмаларының Россия Федерациясе Үзәк банкына тапшырыла торган хисаплылык исемлеге, формалары һәм аларны төзү һәм бирү тәртибе турында» 2018 елның 8 октябрендәге 4927-У номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Банкның 4927-У номерлы күрсәмәсе)» сүзләрен «Кредит оешмаларының (банк төркемнәренең) Россия Федерациясе Үзәк банкына тапшырыла торган хисаплылыкны төзү һәм кертү формалары, сроклары, тәртибе турында, шулай ук кредит оешмалары (банк төркемнәре) эшчәнлеге турында мәгълүмат исемлеге хакында» 2023 елның 10 апрелендәге 6406-У номерлы күрсәтмәсе (алга таба – Банкның 6406-У номерлы күрсәтмәсе)» сүзләренә алмаштырырга;

«к» пунктчасында «Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «Банкның 6406-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

«л» пунктчасында «Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «Банкның 6406-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга;

«м» пунктчасында «Банкның 4927-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләрен «Банкның 6406-У номерлы күрсәтмәсе» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин